**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

16.01.2025 19-п

Казылма чыгару оешмасының уртача еллык куәтенә исәпләгәндә салым суммасының исәпләнгән зурлыгының минималь процентын билгеләүче «П» коэффициенты күрсәткечләрен билгеләү һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланган өчен бер тапкыр түләүнең башлангыч күләмен исәпләп чыгару тәртибен раслау турында» 2019 елның 6 маендагы 458-п номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип тану хакында

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 40 статьясындагы 2 өлеше, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләүнең минималь (старт) күләмен исәпләү методикасының 5 пункты, Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның «Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләүнең минималь (старт) күләмен исәпләү методикасын билгеләү турында» 2022 елның 31 мартындагы 242/01 номерлы боерыгы нигезендә боерык бирәм:

1. Бер тапкыр түләүнең минималь (старт) күләмен исәпләгәндә, 2025-2026 елларда казылма чыгару оешмасының уртача еллык куәтенә исәпләгәндә салым суммасының исәпләнгән зурлыгының минималь процентын характерлый торган «П» коэффициенты күрсәткечләрен 1 гә тигез итеп билгеләргә.

2. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына аукцион Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән, шулай ук федераль яисә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә кертелмәгән җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына аукцион үткәрү тәртибе турында» 2021 елның 28 декабрендәге 2499 номерлы карары белән расланган Федераль әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән, шулай

ук федераль яисә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә кертелмәгән җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына электрон рәвештә аукцион үткәрү кагыйдәләренең 78 пунктындагы «а» пунктчасында каралган нигез буенча булмаган дип танылган очракта (аукционда катнашуга гаризалар булмау), җир асты байлыкларының мондый кишәрлегенә карата аукцион үткәрү турында һәр кабат карар кабул ителгәндә, «П» коэффициенты күрсәткече тиешенчә -0,7, -0,4, -0,1 күләмендә билгеләнә.

3. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланган өчен бер тапкыр бирелә торган түләүнең башлангыч күләмен исәпләү тәртибен раслау турында» 2019 елның 6 маендагы 458-п номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Тугушевка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков